КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 ноябрь г.Казань № 898

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 122 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 122 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 октябрь, 794 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү чыгымнары

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын тормышка ашыруга ел саен күздә тотыла торган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 27 февраль, 122 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 24 ноябрь, 898 нче
карары редакциясендә)

**Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

1.2. Субсидияләр экологик иминлекне тәэмин итүгә, әйләнә-тирә мохитне саклауга, экология өлкәсендә балалар һәм яшьләр эшчәнлеген үстерүгә, экология культурасын формалаштыруга һәм халыкка экология буенча белем бирүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә бирелә.

1.3. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет акчасы алучы буларак Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.4. Коммерциягә карамаган оешмаларның субсидияләр алу хокукына конкурс (алга таба – конкурс) үткәрүне оештыру, шулай ук коммерциягә карамаган оешмалар белән субсидияләр бирү турында килешүләр (алга таба – килешү) төзү Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.5. Вәкаләтле орган бу Тәртип кысаларында:

конкурс турында игълан итә;

конкурс, конкурста катнашучыларга карата таләпләр һәм аның йомгаклары турындагы мәгълүматны «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керүче вәкаләтле органның

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтында урнаштыра;

конкурста катнашу өчен гаризалар (алга таба – гаризалар) әзерләү мәсьәләләре буенча консультация бирүне оештыра;

гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

бирелгән гаризаларның сакланышын тәэмин итә;

коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә субсидияләр бирү буенча конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

коммерциягә карамаган оешмалар – конкурста җиңүчеләр белән килешүләр төзи;

бирелгән субсидияләрнең максатчан һәм нәтиҗәле файдаланылуын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

## 2. Конкурс комиссиясе

2.1. Конкурс комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

конкурсның һәр өстенлекле юнәлеше буенча экспертлар исемлеген төзи һәм раслый;

конкурста катнашырга рөхсәт ителгән коммерциягә карамаган оешмалар исемлеген һәм конкурста катнашырга рөхсәт ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар исемлеген раслый;

коммерциягә карамаган оешмаларның гаризаларына эксперт бәясе нәтиҗәләрен карый һәм, кирәк булганда, бирелгән гаризалар буенча барлыкка килә торган мәсьәләләрне ачыклау максаты белән утырышларга коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләрен чакыра;

номиналь коэффициент күләме турында карар чыгара;

гариза рейтингының иң чик мәгънәсен билгели, шуның белән әлеге гаризаны тапшырган конкурста катнашучы җиңүче дип таныла;

һәр өстенлекле юнәлешләр буенча конкурста җиңүчеләрне билгели.

2.3. Конкурс комиссиясе үз утырышын әгъзаларының кимендә өчтән икесе булганда үткәрә. Конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, аның өчен конкурс комиссиясендә катнашучы әгъзалар 50 проценттан артыграк тавыш бирсәләр, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис итүченең тавышы хәлиткеч тавышка ия була.

2.4. Конкурс комиссиясе карарлары аның утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куйган конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана. Конкурс комиссиясе әгъзаларының үз фикере булса, бу фикерләр шулай ук конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә.

Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында беркетмә расланган көннән өч көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

2.5. Конкурс комиссиясе әгъзасы конкурс йомгаклары белән шәхсән (турыдан-туры яки читләтеп) кызыксынган яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясый ала торган башка хәлләр булган очракта, ул конкурста катнашу турындагы гаризаларны карап тикшерә башлаганга кадәр бу турыда конкурс комиссиясенә язмача хәбәр итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе әгъзасының шәхсән кызыксынуы – аның конкурс комиссиясе әгъзасы, аның якын туганнары – ире, хатыны, ата-анасы, балалары, уллыкка алучылар, уллыкка алынганнар, бертуган абыйлары - энеләре һәм бертуган апалары - сеңелләре, бабасы, әбисе, оныклары, шулай ук конкурс комиссиясе әгъзасы финанс йөкләмәләре яки башка йөкләмәләр белән бәйле булган гражданнар һәм оешмалар өчен акчалата йә натураль формада, турыдан-туры матди файда рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге дип аңларга кирәк.

Конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясарга мөмкин булган сәбәпләргә түбәндәгеләр керә:

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының, гамәлгә куючы, күмәк орган әгъзасы, бер үзе хуҗа булган башкарма орган яки хезмәткәр буларак, конкурста катнашучы булып торучы оешма эшчәнлегендә (шул исәптән соңгы 12 ай дәвамында) катнашуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы оешманың гамәлгә куючысы, конкурста катнашучысы, әгъзасы булып торучы оешма эшчәнлегендә гамәлгә куючы, яки бер үзе хуҗа булган башкарма орган сыйфатында (шул исәптән соңгы 12 ай дәвамында) катнашуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы оешма белән шартнамәле мөнәсәбәтләрдә (шул исәптән соңгы биш ел дәвамында) булуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы оешмадан акча, башка мөлкәт, матди файда (шул исәптән түләүсез башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр рәвешендә) (шул исәптән соңгы биш ел дәвамында) алуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы оешма, аның гамәлгә куючысы, җитәкчесе, хезмәткәре белән суд бәхәсләре (шул исәптән соңгы биш ел дәвамында) булуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының конкурста катнашучы булып торучы оешма эшендә ихтыярый зат сыйфатында (шул исәптән соңгы 12 ай дәвамында) катнашуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының шәхси кызыксынуы белән конкурс комиссиясе функцияләре арасында каршылыклар килеп чыга яки килеп чыгарга мөмкин булган башка хәлләр.

Конкурс комиссиясе, әгәр дә аңа конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясый ала торган хәлләр булу турында билгеле булса, конкурс комиссиясе әгъзасының язма гаризасын алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә аларны карарга һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә тиеш:

конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуын туктатып торырга;

конкурс комиссиясе әгъзасы шәхсән кызыксына торган конкурста катнашу турындагы гаризаларны яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясый ала торган башка хәлләр булган конкурста катнашу турындагы гаризаларны тикшерүдә конкурс комиссиясе әгъзасын катнаштырмыйча яки конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясе әгъзасы булмаганда карап тикшерергә;

конкурс йомгакларында конкурс комиссиясе әгъзасының шәхсән кызыксынуы булмау турында игълан итәргә.

Конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс йомгаклары белән шәхсән кызыксынуы яки конкурс комиссиясе эшендә конкурс комиссиясе әгъзасының катнашуына йогынты ясый ала торган башка хәлләр булу турында мәгълүмат, шулай ук мондый мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе кабул иткән карарлар конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә күрсәтелә.

## 3. Конкурсның төп бурычлары, принциплары һәм юнәлешләре

3.1. Конкурс үткәрүнең төп бурычлары – түбәндәгеләр:

дәүләт хакимияте органнарының һәм коммерциягә карамаган оешмаларның социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүдә үзара хезмәттәшлеге формаларын камилләштерү;

коммерциягә карамаган оешмаларның гражданлык җәмгыяте институтларын үстерүдәге ролен арттыру;

коммерциягә карамаган оешмаларның социаль әһәмиятле эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм аны үстерү.

3.2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү эше түбәндәге принципларга нигезләнә:

гавами булу;

конкурс турында мәгълүмат ачык булу;

коммерциягә карамаган оешмаларның конкурста катнашуга хокуклары тигез булу;

экспертлар фикерләрен исәпкә алу;

ярышу, гаризаларны карап тикшерү конкурс нигезендә булу.

3.3. Конкурс түбәндәге өстенлекле юнәлешләр буенча үткәрелә:

экологик иминлекне тәэмин итү;

экологик культураны формалаштыру;

кече шәһәрләрдә һәм авыл җирлегендә гражданлык җәмгыятьләре институтларын үстерүгә юнәлдерелгән социаль әһәмиятле экологик белем бирү һәм мәгърифәтчелек проектларын тормышка ашыруда булышлык күрсәтү;

туган якны өйрәнү һәм экологик туризм өлкәсендә эшчәнлекне үстерү.

## 4. **Конкурста катнашучыларга карата таләпләр**

4.1. Татарстан Республикасы территориясендә законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үзләренең гамәлгә кую документлары нигезендә

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 гыйнвар, ФЗ-7 нче Федераль законның 31[1] статьясы белән күздә тотылган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы һәм түбәндәге таләпләргә җавап бирүче коммерциягә карамаган оешмаларга конкурста катнашырга рөхсәт ителә:

сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр рәвешендә коммерциягә карамаган оешмалар, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр булып тормаган;

килешү төзү планлаштырыла торган айдан алдарак килә торган айның беренче көненә:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча түләнмәгән бурычлары булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка норматив актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормаган;

чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булмаган;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокук актлары нигезендә акча алучылар булмаган.

4.2. Конкурсны үткәрмәү өчен нигезләр – түбәндәгеләр:

бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау;

коммерциягә карамаган оешмаларның гаризалары булмау.

Конкурс үткәрмәү турындагы карар конкурс комиссиясенең чираттагы утырышында ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, аның өчен конкурс комиссиясендә катнашучы әгъзалар 50 проценттан артыграк тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис итүченең тавышы хәлиткеч тавышка ия була.

Конкурс комиссиясе карары аның утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куйган конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

Конкурс үткәрмәү турындагы игълан конкурс үткәрмәү турында карар кабул ителгән көннән өч көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

## 5. Гаризалар бирү тәртибе

5.1. Конкурс үткәрү турындагы игълан конкурс үткәрү турында карар кабул ителгән көннән өч көн эчендә вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла. Игъланда конкурс үткәрү вакыты, урыны, предметы һәм тәртибе, гаризаларны кабул итә башлау һәм кабул итү тәмамлану турында мәгълүматлар булырга тиеш.

Гаризаларны кабул итү конкурс үткәрү турындагы игълан вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 14 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Конкурста катнашу өчен вәкаләтле органга, түбәндәгеләрне теркәп, бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча гариза кертелә:

Бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән һәм тормышка ашыру вакыты 12 айдан да артыграк булмаган проектны бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча;

коммерциягә карамаган оешма уставы күчермәсен;

гаризалар кабул итә башларга кимендә өч ай кала бирелгән гариза бирүче турындагы мәгълүматлар белән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан күчермәне. Коммерциягә карамаган оешма Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан күчермәне кертмәсә, вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген җайга салучы федераль законнарның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2006 ел, 15 апрель, 212 нче карары нигезендә гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә кертелгән үткән финанс елы өчен хисаплылык күчермәсен;

конкурста катнашу турындагы гариза бирү көненнән алда килгән көнгә кадәр булган бер ай хәленә карата Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүчеләр (җыемнар түләүчеләр, иминият кертемнәре түләүчеләр, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләрнең үтәлүе турында белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон рәвештә кертү форматын раслау турында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча белешмә кәгазен;

Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән бурычы булмауны раслый торган һәм коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер тарафыннан кул куелган белешмә кәгазен;

коммерциягә карамаган оешма үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормау турында белешмә кәгазен;

коммерциягә карамаган оешма бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормауны раслый торган документларны.

Коммерциягә карамаган бер оешма бары тик бер генә гариза бирә ала, аның составында конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен бер проект кына тәкъдим ителә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тегелергә, аларда бит саннары куелырга тиеш, алар коммерциягә карамаган оешманың мөһере һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланырга тиеш. Барлык документлар ачык итеп җыелган булырга тиеш.

Кырулар һәм төзәтүләр (мөһер белән беркетелгән һәм коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар кәгазь һәм электрон чыганакларда (doc һәм pdf формаларында) турыдан-туры вәкаләтле органга кертелә яки аңа почта аша җибәрелә.

Гаризалар кабул итү вакыты төгәлләнгәннән соң вәкаләтле органга кергән (шул исәптән почта аша) гариза теркәүгә алынмый һәм конкурста катнаша алмый.

5.3. Гаризаны кабул иткәндә вәкаләтле орган аны кергән көнендә конкурста катнашу турындагы гаризаларны исәпкә алу журналында терки һәм коммерциягә карамаган оешмага, гаризаны алу датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, аны алу турында расллама кәгазе бирә.

Гариза вәкаләтле органга почта аша кергәндә ул гаризаларны исәпкә алу журналында бер көн эчендә теркәлә. Бу очракта гаризаны алу турында расллама язылмый, гаризаларны исәпкә алу журналында теркәү көне итеп почта аша җибәрелә торган әйбердәге штемпель белән расланган почта аша җибәрелә торган әйберне элемтә оешмасына тапшыру көне күрсәтелә.

5.4. Тапшырылган гаризалар вәкаләтле орган гаризаларны кабул итеп бетергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү буенча тикшерә.

5.5. Әгәр дә гариза бу Тәртип таләпләренә туры килсә, ә гариза биргән коммерциягә карамаган оешма бу Тәртип белән аңа карата куелган таләпләргә туры килсә, ул конкурс комиссиясе тарафыннан туры килә дип санала.

Конкурс комиссиясе түбәндәге очракта гаризадан баш тарту турында карар кабул итә:

гариза бу Тәртипнең таләпләренә туры килми;

гаризада дөрес булмаган мәгълүматлар булу;

гариза биргән коммерциягә карамаган оешма бу Тәртип белән куела торган таләпләргә туры килми;

таләп ителә торган документларны тапшырмау (яки тулы күләмдә тапшырмау).

5.6. Туры килә торган дип танылган гаризаларны һәм аңа теркәлә торган документларны вәкаләтле орган бу Тәртипнең 5.4 нче пункты белән билгеләнгән вакыт чыкканнан соң конкурс комиссиясе тарафыннан расланган экспертлар исемлегенә кертелгән экспертларга карап тикшерүгә тапшыра.

## 6. Гаризаларны бәяләү критерийлары һәм тәртибе

6.1. Гаризаларны бәяләү экспертлар тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

| Т/с | Коммерциягә карамаган оешмаларның гаризаларын бәяләү критерийлары | Бәя (баллар) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Конкурсның өстенлекле юнәлеш-ләренә туры килү | Баллар саны кертелгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 2. | Проект хәл итәргә йөз тоткан бурычларның актуальлеге | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 3. | Проект чараларының логикалы, үзара бәйләнешле һәм эзлекле булуы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 4. | Проектны тормышка ашыруга планлаштырыла торган чыгым-нар һәм аның көтелә торган нәтиҗәләре нисбәте | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 5. | Проектны тормышка ашыру чыгымнарының нигезле булу-булмавы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 6. | Проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу, аларның проект бурычларына туры килү-килмәве | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 7. | Планлаштырылган чараларның проектны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә туры килү-килмәве | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 8. | Проект чараларының максатчан төркем хәлен яхшыртуга тәэсир итү дәрәҗәсе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 9. | Коммерциягә карамаган оешманың проект буенча күздә тотыла торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәҗрибәсе булу | 1 елдан 2 елга кадәр – 1;<br>3 – 5 елга – 2;<br>6 – 8 елга – 3;<br>9 – 10 елга – 4;<br>10 елдан күбрәк – 5. |
| 10. | Коммерциягә карамаган оешманың проектны тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник базасы һәм урыннары булу | Баллар саны кертелгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 11. | Коммерциягә карамаган оешманың максатчан керемнәрдән файдалану тәҗрибәсе булу | Баллар саны кертелгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 12. | Проект челтәрле партнерлыкта үсә | юк – 0,<br>ике коммерциягә карамаган оешма челтәрле партнерлыкта булганда – 1,<br>коммерциягә карамаган оешма һәм бизнес челтәрле партнерлыкта булганда – 2,<br>коммерциягә карамаган оешма, бизнес һәм хакимият челтәрле партнерлыкта булганда – 3,<br>коммерциягә карамаган оешма, бизнес, хакимият һәм массакүләм мәгълүмат чаралары челтәрле партнерлыкта булганда – 4 |
| 13. | Проект берничә муниципаль район һәм (яки) шәһәр округы территориясендә тормышка ашы-рыла | юк – 0;<br>ике муниципаль берәмлектә – 1,<br>өч һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлектә – 3 |
| 14. | Коммерциягә карамаган оешманың «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә эшләнгән сайты булу | юк – 0;<br>әйе – 1. |

6.2. Һәр гариза ике эксперт тарафыннан карап тикшерелә. Әгәр дә проектны карап тикшергән экспертлар бәясе 35 һәм аннан да күбрәк баллга аерылса, проект

конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә торган өченче эксперт тарафыннан карап тикшерелә.

Экспертиза үткәрү барышында билгеле булган мәгълүмат конфиденциаль булып тора һәм таратылырга тиеш түгел.

6.4. Вәкаләтле орган тарафыннан гаризаларны тикшерү беткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә экспертлар гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны карап тикшерәләр, аларны бу Тәртипнең 6.1 нче пункты белән билгеләнгән критерийлар буенча бәялиләр һәм эксперт бәяләмәләрен конкурс комиссиясенә тапшыралар.

Конкурс комиссиясе проектлар рейтингын һәр критерий буенча экспертлар куйган баллар суммасы буенча формалаштыра, ул экспертлар тарафыннан куелган һәр критерий буенча баллар суммасыннан уртача арифметик юл белән исәпләп чыгарыла.

6.5. Экспертлар бәяләмәләрне керткәннән соң, вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә гариза рейтингының минималь мәгънәсен (алга таба – гариза рейтингының минималь мәгънәсе) билгели. Аны керткән конкурста катнашучы җиңүче дип танылырга мөмкин.

Гариза рейтингының минималь мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$М = ОКБ/N ,$$

монда:

М – гариза рейтингының минималь мәгънәсе;

ОКБ – конкурста катнашучылар җыйган балларның барлык суммасы;

N – конкурста катнашучылар саны.

Гариза рейтингының минималь мәгънәсен исәпләп чыгарганнан соң, вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган өч көндә номиналь коэффициент күләме турында карар кабул итү һәм гариза рейтингының иң чик мәгънәсен (алга таба – гариза рейтингының иң чик мәгънәсе) билгеләү өчен конкурс комиссиясе утырышын үткәрүне тәэмин итә, шуның белән бергә аны керткән конкурста катнашучы җиңүче дип танылa.

Гариза рейтингының иң чик мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Р = М \times К,$$

монда:

Р – гариза рейтингының иң чик мәгънәсе;

М – гариза рейтингының минималь мәгънәсе;

К – конкурс комиссиясе карары белән билгеләнә торган, 0,01 адымга артырып, 1 гә тигез булган номиналь коэффициент.

6.6. Гариза рейтингының иң чик мәгънәсен билгеләгәннән соң, конкурс комиссиясе эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә өстенлекле юнәлешләр буенча конкурста җиңүчене билгели.

**7. Субсидияләр бирү һәм алардан файдалану**

7.1. Вәкаләтле орган конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурста җиңүчеләрне билгеләгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Конкурста җиңүчеләргә субсидияләр бирү турында һәм аларга бирелә торган, бу Тәртипнең 7.2 нче пункт нигезендә билгеләнә торган субсидияләр күләме турында яки субсидияләр бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

7.2. Конкурста җиңүчеләргә бирелә торган субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C_i = \frac{S}{SUM} \times a_i,$$

$C_i$ – i-коммерциягә карамаган оешма – конкурста җиңүчегә субсидия күләме;

S – субсидияләр бирү өчен бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме;

SUM – конкурста җиңүче дип танылган барлык коммерциягә карамаган оешмалар җыйган баллар суммасы;

$a_i$ – эксперт төркеме бәяләве буенча i-коммерциягә карамаган оешма – конкурста җиңүче җыйган балларның барлык суммасы.

i-коммерциягә карамаган оешманың бу пункт нигезендә билгеләнгән субсидия күләме i-коммерциягә карамаган оешма сораган субсидия күләменнән артып киткән очракта, i-коммерциягә карамаган оешманың субсидия күләме i-коммерциягә карамаган оешма сораган субсидия күләменә тигез итеп билгеләнә, ә аерма бу пункт нигезендә конкурс буенча сайлап алу аша үткән башка коммерциягә карамаган оешмалар арасында бүленә.

7.3. Субсидияләр бирү турында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары (бирелә торган субсидияләр күләмнәрен күрсәтеп, конкурста җиңүчеләр исемлеге) вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырыла.

7.4. Субсидияләр бирү турында карар кабул иткән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә вәкаләтле орган конкурста җиңүчеләр белән Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы раслаган бертип форма буенча субсидияләр бирү турында килешүләр төзи.

Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлеше, субсидия бтрү нәтиҗәләлелеге күрсәткечләре мәгънәләре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидияне файдалану турында хисап бирү формасы һәм вакытлары, субсидия бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткечләренә ирешү, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия акчасын кире кайтару очрагы, югары технологияле импорт җайланмаларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән башка, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, вәкаләтле орган, дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары һәм Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы тарафыннан субсидия бирү шартларын,

максатларын һәм аны бирү тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрү өчен коммерциягә карамаган оешмасының ризалыгы, килешү шартларын бозган өчен җаваплылык карала.

7.5. Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия күчерү килешү төзегән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә коммерциягә карамаган оешманың исәп-хисап исәбенә килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Коммерциягә карамаган оешма субсидия керү һәм аны сарыф итү буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

7.6. Коммерциягә карамаган оешма субсидияне бирелгән гариза нигезендә максатчан билгеләнеш буенча файдаланырга тиеш. Коммерциягә карамаган оешма, конкурс комиссиясе белән килештереп, аларны тоту юнәлешләре арасында акчаны яңадан бүлү өлешендә бюджет проектына бирелә торган субсидиянең гомуми күләменең 10 проценты чикләрендә үзгәреш кертергә хокуклы.

7.7. Коммерциягә карамаган оешма бирелгән субсидия исәбеннән бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән проект нигезендә түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашырырга хокуклы:

хезмәт өчен түләү буенча;

товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә түләү, аренда түләве буенча;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен түләү һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына башка мәҗбүри түләүләрне кертү буенча;

мөлкәти хокуклар, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокуклар сатып алу буенча;

командировкалар буенча;

ихтыярый затлар чыгымнарын каплау буенча;

проектны тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнар буенча.

7.8. Коммерциягә карамаган оешмага бирелгән субсидия исәбеннән түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру рөхсәт ителми:

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм коммерция оешмаларына ярдәм күрсәтүгә бәйле булган;

бу Тәртипнең 1.2 нче пунктында күрсәтелгән проектларга турыдан-туры бәйле булмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга;

сәяси партияләргә һәм сайлау кампанияләренә булышлык күрсәтүгә;

митинглар, демонстрацияләр, пикетлар үткәрүгә;

фундаменталь фәнни тикшеренүләргә;

алкогольле эчемлекләр һәм тәмәке продукциясе сатып алуга;

штрафлар түләү буенча;

югары технологияле импорт җайланмаларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән башка, чит ил валютасы сатып алу буенча.

## 8. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

8.1. Коммерциягә карамаган оешманың субсидиядән файдалану турында хисаплылык кертү формасы һәм вакытлары субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнә.

8.2. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерү гамәлгә ашыра.

8.3. Субсидия түбәндәгеләр ачыкланган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарыла:

субсидияләрдән максатчан файдаланмау яки билгеләнгән вакытларда файдаланмау;

вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнүче шартларны бозу;

килешүдә билгеләнә торган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү.

8.4. Килешүдә каралган һәм хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия коммерциягә карамаган оешма тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш.

8.5. Субсидия алучы аны кире кайтару өчен билгеләнгән вакытны бозса, вәкаләтле орган вакыт чыккан көннән утыз көн эчендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару чараларын күрә.

Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү хокукына конкурста катнашуга
ГАРИЗА

1. Оешма-гариза бирүче исеме һәм адресы:
Исеме:
____________________________________________________________________________
Адресы: _____________________________________________________________
(индексы) (юридик адресы)
_____________________________ E-mail: __________________________________
(телефоны) (факсы)
Оешманың «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты __
____________________________________________________________________________
2. Оешма җитәкчесе _____________________________________________________
Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) _____________________
тел.: ____________________
Адресы: ________________________________________ E-mail: _______________
3. Оешма-гариза бирүче гамәлгә ашыра торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
4. Проект турында мәгълүмат.
Проектның исеме: ______________________________________________________
Проектның юнәлеше: ___________________________________________________
Проектның авторы: _____________________________________________________
Элемтә өчен мәгълүмат: _________________________________________________
5. Оешма-гариза бирүченең элек дәүләт ярдәмен яки муниципаль ярдәмне алганы булдымы? Әгәр дә булса, проектның исемен, елын суммасын күрсәтегез:
____________________________________________________________________________
6. Проектка кыскача тасвирламасы (100 сүздән дә артмаска тиеш).

Мәсьәлә тасвирламасы: ______________________________________________________
______________________________________________________________________________
Проектның максаты һәм бурычлары: ___________________________________________
Чаралар планы: _________________________________________________________
______________________________________________________________________________
Проектны тормышка ашыруга җәлеп ителергә планлаштырыла торган ихтыярый затлар саны: _______________________________________________________________
Көтелә торган нәтиҗәләре: ________________________________________________
______________________________________________________________________________
Проектның бюджеты: _____________________________________________________
______________________________________________________________________________
Проектның кирәклеген нигезләү:
______________________________________________________________________________
Кушымталар CD, DVD-йөрткечләрдә һәм басма рәвештә (видеоматериаллар, фотосурәтләр, басма продукция һ.б.) кертелә.
7. Түләү реквизитлары:
Банкның исеме: ___________________ адресы: _________________________________
хисап исәбе (р/с): ______________________________ ИНН _________________________

Моның белән гаризада, коммерциягә карамаган оешманың Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе таләпләренә туры килүен белдерәм. Гаризада, проектның тасвирламасында күрсәтелгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар дөрес һәм төгәл булып тора. Вәкаләтле органның тапшырылган мәгълүматларны тәгаенли торган мәгълүматны бездән һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарыннан соратып алырга хокуклы булуын раслыйм.

Оешма-гариза бирүче
җитәкчесе _ _____________________ / ______________________/
(имзасы) (имза тулысынча)

М.У. Датасы: _______________________

Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы тарафыннан тутырыла
Теркәү номеры ____________________

Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү хокукына конкурста катнашуга
ПРОЕКТЫ

(100 сүздән дә артмаска тиеш)

1. Проектны тормышка ашыра башлау вакытына хәлнең гомуми тасвирламасы (иң күбе 2 бит):

| |
|---|
| |

2. Проектның максатлары һәм бурычлары:

| |
|---|
| |

3. Төп чараларны тасвирлау, проектны гамәлгә ашыру этаплары һәм вакытлары:

| Т/с | Чаралар исеме | Тормышка ашыру вакытлары |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

4. Проектны тормышка ашыру белән идарә итү механизмы:

| |
|---|
| |

5. Керер дип күздә тотыла торган акча һәм планлаштырыла торган чыгымнар сметасы, аларны нигезләү:

Чыгымнарның барлык суммасы (сум):

Субсидиянең сорала торган күләме (сум):

(сум)

| Т/с | Чыгымнар исеме | Үз акчасы | Сорала торган акча | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| Барлыгы | | | | |

Комментарийлар: ________________________________________________________
________________________________________________________________________

6. Проектны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре:

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

7. Партнерлар турында мәгълүмат:

| |
|---|
| |

Кушымталар CD, DVD-чыганакларда, электрон һәм басма рәвештә (видеоматериаллар, фотографияләр, басма продукция һ.б.) кертелә.

____________________________________________________________ / __________________/
(Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (имзасы)
(соңгысы – булганда)